**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ВЕРХНЕ-ЧЕРШИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**ул. Ленина, дом 29а. с. Верхние Чершилы, 423364 телефон (85559) 4-21-41**

ОКПО: 93068462 ОГРН:103160400100
ИНН: 1636001964 КПП: 163601001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Югары Чыршылы авылы, Ленин урамы, 29а йорты, 423364, телефон (85559) 4-21-41**

ОКПО: 93068462 ОГРН: 103160400100
ИНН: 1636001964 КПП: 163601001

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17 » сентябрь 2018 г. № 14

## Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы карары:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: "2019 елда Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлек студентларыннан тыш, жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча һәр кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән килешәсезме?:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә, шул исәптән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: - кышкы чорда Югары Чыршылы, Түбән Чыршылы, Усай авылларындагы юлларны кардан чистарту; - Түбән Чыршылы т. п., Горький ур.;
2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү, шул исәптән: - Усай авылында янгын краны сатып алу һәм урнаштыру;
3. Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру, шул исәптән: - зират территориясен коймa белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары, Усай, Түбән Чыршылы, Югары Чыршылы зиратлары өчен инвентарь, җиһазлар сатып алу.;
4. Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән: - Югары Чыршылы, Усай авылларында Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр алу;

5. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- Югары Чыршылы, Усай торак пунктларында югары агачлар кисү;
- Югары Чыршылы авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәл кую һәм төзелеш материаллары сатып алу;;

Әйе ЮК?

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге
Советы Рәисе И.Н.Камалетдинов